**Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение**
**«Бишнинская основная общеобразовательная школа Зеленодольского муниципального района Республики Татарстан»**

| | | |
|---|---|---|
| **«Рассмотрено»**<br>Руководитель ШМО гуманитарных предметов<br>_________ / З. Ю. Файзиева/<br>Протокол № _____<br>от «_31_» ___08___ 2023 г. | **«Согласовано»**<br>Заместитель директора по УР<br>_________ /Г. Ю. Гарифуллина/<br>«_31_» ___08___ 2023 г. | **«Утверждено»**<br>Директор школы<br>_________ /З. М. Сабирова/<br>Приказ №_135-ОД_ «_31_» ___08___ 2023 г. |

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

**по родному (татарскому) языку**

**в 3 классе**

**Закировой Айсылу Наильевны, учителя начальных классов**

Рассмотрено на заседании
педагогического совета школы.
Протокол №__ от «___» ___________ 2023 года

**2023-2024 учебный год**

## Пояснительная записка

Рабочая программа учебного предмета «**«Родной( татарский) язык»** (далее Рабочая программа) составлена в соответствии со следующими нормативно-правовыми документами:

1.Федеральным Законом «Об образовании в Российской Федерации» от 29 декабря 2012 г. № 273-ФЗ,

2. Федеральным государственным образовательным стандартом начального общего образования второго поколения, утвержденным приказом Министерства образования и науки Российской Федерации от 6 октября 2009 года,№373

3. Приказом МО и Н РФ от 31.12.2015 № 1576 «О внесении изменений в Федеральный государственный образовательный стандарт начального общего образования, утвержденный приказом Министерства образовании и науки РФ от 6.10.2009 №373»,

4.Основной образовательной программой начального общего образования МБОУ «Бишнинская основная общеобразовательная школа ЗМР РТ»;

5.Уставом МБОУ «Бишнинская основная общеобразовательная школа ЗМР РТ»;

6.Учебным планом МБОУ «Бишнинская основная общеобразовательная школа ЗМР РТ» на 2023-2024 учебный год;

7. Положением о структуре, порядке разработки и утверждения рабочих программ педагогов Муниципального бюджетного общеобразовательного учреждения «Бишнинская основная общеобразовательная школа Зеленодольского муниципального района Республики Татарстан».

## Общая характеристика программы

Отличительной особенностью курса родного (татарского) языка и литературного чтения является коммуникативно-познавательная основа. Содержание этого курса имеет ярко выраженную коммуникативно-речевую и познавательную направленность, охватывающую три аспекта изучения родного языка: систему языка, речевую деятельность и литературный текст, что обеспечивает реализацию в обучении системно-деятельностного подхода.

## Основные цели и задачи изучения предмета в начальной школе

В системе предметов начальной общеобразовательной школы предмет «Родной (татарский) язык » реализует две основные цели:

1) познавательную (ознакомление с основными положениями науки о языке и формирование на этой основе знаково-символического восприятия и логического мышления учащихся);

2) социокультурную (формирование коммуникативной компетенции учащихся: развитие устной и письменной речи, монологической и диалогической речи, а также навыков грамотного, безошибочного письма как показателя общей культуры человека**).**

Основные задачи содержания учебного предмета:

-формировать первоначальные представления о единстве и многообразии языкового и культурного пространства России, о языке как основе национального самосознания;

-развивать диалогическую и монологическую устную и письменную речь;

-развивать коммуникативные умения;

-иметь представления о правилах речевого и неречевого поведения в процессе общения;

-развивать начальные умения в области слушания, говорения, чтения и письма;

-развивать нравственные и эстетические чувства;

-развивать способности к творческой деятельности;

-развивать потребности в учебном сотрудничестве с одноклассниками и учителем.

## Описание места изучаемого предмета

Программа составлена на 34 учебные недели (136 часов) из расчета 4 учебных часа в неделю.

## Результаты изучения учебного предмета

### Личностные результаты

Учащийся научится:

- испытывать чувство гордости за свою Родину, российский народ и историю России при работе с текстами об истории и культуре нашей страны, древних и современных городах, известных людях;
- осознавать свою этническую и национальную принадлежность;
- относиться с уважением к представителям других народов;
- уважительно относиться к иному мнению;
- понимать практическую значимость получаемых знаний по татарскому языку;
- соблюдать правила поведения на уроке и в классе;
- развивать навыки сотрудничества с одноклассниками и со взрослыми;
- конструктивно разрешать проблемные ситуации;
- оценивать свои успехи в освоении языка.

Учащийся получит возможность:

- сформировать целостный социально ориентированный взгляд на мир в его органичном единстве и разнообразии природы, народов, культур и религий; воспринимать окружающий мир как единый «мир общения»;
- эффективно общаться с окружающим миром (людьми, природой, культурой) для успешной адаптации в обществе;
- сформировать и использовать свои коммуникативные и литературно-творческие способности;
- осваивать духовно-нравственные ценности при работе с текстами о мире, обществе, нравственных проблемах;
- стремиться совершенствовать свою речь и общую культуру;
- сформировать эстетические чувства при работе с поэтическими и прозаическими произведениями.

**Метапредметные результаты**

Учащийся научится:

- ориентироваться в пространстве учебника с помощью знаков навигации;
- понимать цели и задачи учебной деятельности;
- находить ответы на проблемные вопросы;
- самостоятельно оценивать свои достижения или промахи;
- пользоваться знаково-символическими средствами в учебных целях (схема речевого общения, рисунок-схема состава слова, рисунок-схема частей речи);
- пользоваться справочной литературой (словарями);

- развивать логическое мышление при сравнении различных языковых единиц (слово, словосочетание, предложение; главные и второстепенные члены предложения и др.) и при классификации языковых единиц по различным критериям;
- развивать речь при анализе художественных и научных текстов и при составлении собственных текстов различных видов.

Учащийся получит возможность научиться:

- делать самостоятельные выводы;
- находить выход из проблемных ситуаций;
- определять цель и дидактическую значимость предлагаемых учебных заданий;
- выступать в разных ролевых функциях (учитель — ученик), предусмотренных заданиями.

**Предметные результаты**

**Развитие речи. Речевое общение**

Учащийся научится:

- понимать, что язык является главным средством общения людей, помогающее выразить мысли и чувства;
- относиться к татарскому языку как к великой ценности и культурному достоянию народа;
- анализировать речевую модель общения: речь партнера (собеседника) по общению, цель и тему общения, его результат;
- понимать речевые задачи общения: что-то сообщить (проинформировать, известить), одобрить (поддержать, похвалить, согласиться, подтвердить), возразить (оспорить, покритиковать, убедить), объяснить (уточнить, побудить, доказать, посоветовать, воодушевить);

- выбирать языковые средства в зависимости от ситуации общения;
- контролировать и корректировать своё высказывание в зависимости от ситуации общения;
- правильно использовать в общении вспомогательные средства: мимику, жесты, выразительные движения, интонацию, логические ударения, паузы в соответствии с культурными нормами;
- различать диалогическую и монологическую речь;
- составлять диалоги, основанные на известных правилах продуктивного общения;
- составлять устные тексты различных типов: повествование, описание, рассуждение;
- пересказывать текст с помощью опорных слов, с ориентировкой на главную мысль высказывания;
- писать изложения по составленному плану;
- составлять рассказы по серии картинок, на предложенную тему, по личным впечатлениям.

Учащийся получит возможность научиться:

- совершенствовать свою устную речь на фонетическом, лексическом и синтаксическом уровнях;
- говорить выразительно, понятно, логично, чётко формулируя мысль в словесной форме; говорить связно в нормальном темпе, соблюдая необходимые нормы орфоэпии;
- делать полный и краткий пересказ текста;
- устранять в текстах шаблонные фразы и выражения, передавать своё отношение к высказанному;
- совершенствовать культуру речевого общения: соблюдать нормы речевого этикета, уметь выразить просьбу, пожелание, благодарность, извинение; уметь поздравить или пригласить друзей, вести разговор по телефону, правильно обратиться к собеседнику;

- соблюдать культуру письменного общения: писать буквы, предложения в соответствии с правилами русской графики и орфографии, соблюдать аккуратность в ведении записей, чёткость и аккуратность выполнения письменных работ.

**Требование к уровню подготовки учащихся по предмету**

К концу учебного года учащийся должен знать: изученные части речи: имя существительное, имя прилагательное, личные местоимения, глагол; однородные члены предложения; особенности каждой части речи; правила правописания падежных окончаний имен существительных и имен прилагательных, личных окончаний глаголов; морфемный состав слов и правописание корней слов; морфологический анализ частей речи (разбор); что такое текст, однородные члены предложения, виды текста.

Ученик должен уметь: безошибочно и каллиграфически правильно списывать и писать под диктовку текст (55-60 слов) с изученными орфограммами; проводить фонетических разбор слов; проводить морфемный анализ слов; проводить разбор слов как части речи; (морфологический);производить элементарный синтаксический разбор предложений; писать изложение текста в 70-85 слов по самостоятельно составленному плану, небольшой рассказ о случае из жизни, о наблюдениях на экскурсиях.

Правильно строить предложения; уметь находить орфографические и синтаксические, речевые ошибки; обобщать знания о составе слова, о частях речи, о предложении, об однородных членах предложения; применять знания в практической деятельности (составлять схемы, таблицы, моделировать предложения); устанавливать причины следствия связи.

Использовать приобретённые знания и умения в практической деятельности и повседневной жизни для:

• адекватного восприятия звучащей речи – рассказ учителя, высказывания сверстников, детские радиопередачи, аудиозаписи и др.;

• работы со словарем: толковым, орфографическим, словарем синонимов и антонимов;

• соблюдения орфоэпических норм;

• создания несложных монологических текстов на доступные детям темы в форме повествования и описания;

• передачи в письменной форме несложных текстов по интересующей младшего школьника тематике;

• владения нормами татарского речевого этикета в ситуациях повседневного и учебного общения: приветствие, прощание, благодарность, поздравительная открытка, письмо другу.

## Содержание учебного предмета

### Лексика. Слово

Слово и его лексическое значение. Однозначные и многозначные слова, их различение. Прямое и переносное значение слова, употребление в собственной речи. Заимствованные слова в татарском языке. Синонимы и антонимы, омонимы: использование в речи. Словарное богатство татарского языка. Словари татарского языка: толковый словарь татарского языка, словари синонимов, антонимов, омонимов и их использование в учебной деятельности и повседневной жизни.

### Состав слова и словообразование

Понятие об однокоренных словах, их отличия от синонимов и омонимов. Однокоренные слова и различные формы одного и того же слова.

Выделение и определение значимых частей слова: корня слова и аффикса. Понятие о словообразовательных и словоизменяющих аффиксах. Разбор слова по составу. Выполнение упражнений с элементами словообразовательного анализа.

Разные способы проверки правописания слов: изменение формы слова; подбор однокоренных слов; использование орфографического словаря.

**Морфология**

Понятие о частях речи.

Имя существительное. Значение и употребление. Формы единственного и множественного числа. Правописание аффиксов множественного числа. Названия и вопросы падежей. Склонение имен существительных. Выполнение упражнений на морфологический анализ существительных.

Глагол. Значение глагола и употребление в речи. Положительная (утвердительная) и отрицательная формы глаголов. Спряжение глаголов. Формы настоящего, прошедшего и будущего времени изъявительного наклонения. Правописание аффиксов будущего времени изъявительного наклонения: -ар, -әр, -ыр, -ер, -р, -ачак, -әчәк, -ячак, -ячәк(практическое овладение).

Морфологический анализ глаголов.

Имя прилагательное. Значение и употребление в речи. Степени сравнений имен прилагательных: положительная, сравнительная, превосходная, уменьшительная. Правописание аффиксов сравнительной степени: - рак, -рәк и частиц в превосходной степени.

Местоимение. Общее представление о местоимении. Личные местоимения, значение и употребление в речи. Личные местоимения 1, 2, 3-го лица, единственного и множественного числа. Склонение личных местоимений

Частицы. Приемы и способы различия частиц *да, дә, та, тә* от аффиксов местно-временного падежа *–да, -дә, -та, -тә*. Правописание частиц.

Послелоги, их значение в речи. Употребление послелогов с именами существительными и местоимениями в разных падежах.

**Синтаксис**

Предложение. Разновидности предложений по цели высказывания (повествовательные, вопросительные и побудительные). Знаки препинания в конце предложения: точка, вопросительный и восклицательный знаки. Интонационные особенности повествовательных, побудительных, вопросительных и восклицательных предложений (практическое усвоение).

Понятие о главных и второстепенных членах предложения. Подлежащее и сказуемое. Установление связи слов в предложении. Порядок слов в предложении.Понятие о нераспространенных и распространенных предложениях.

Словосочетание. Сходство и различие предложения, словосочетания, слова. Различение главного и зависимого слова в словосочетании.

**Развитие речи**

Текст. Определять тему, основную мысль текста, делить его на абзацы. Особенности описательного, повествовательного текста.

Знакомство с речевым этикетом.

**Тематическое планирование с определением основных видов**

**учебной деятельности**

| | | |
|---|---|---|
| Повторение изученного материала в 1-2 классах | 16 | Распознавать звонкие, глухие согласные и гласные звуки; находить в словах изученные орфограммы и объяснять написание слов,<br>использовать орфографические словари.<br>Делить слова на слоги и определить их количество. Перенос слов по слогам. Находить и исправить ошибки, допущенные при переносе слов с одной строки на другую. Использовать знание алфавита в работе с орфографическим и орфоэпическим словарями. |
| Лексика. Слово | 10 | Различать однозначные и многозначные слова, прямое и переносное значения слова, наблюдать за использованием в тексте, в собственной речи слов в переносном значении<br>Отличать однокоренные слова от синонимов и омонимов. Находить в тексте синонимы и антонимы. |
| Состав слова и словообразование | 9 | Членить слова на корень и аффикс. Отличать словообразовательные аффиксы от словоизменяющих аффиксов.<br>Отличать однокоренные слова от синонимов и омонимов.<br>Различать способы словообразования слов. |
| Морфология.<br>Имя существительное | 16 | Различать части речи: существительное, прилагательное, местоимение, глагол.<br>Распознавать одушевлённые и неодушевлённые, собственные и нарицательные имена существительные;<br>изменять существительные по числам и падежам; различать названия падежей. |

| | | |
|---|---|---|
| Глагол | 27 | Изменять глаголы по временам и числам. Спрягать глаголы изъявительного наклонения настоящего, прошедшего и будущего времени. |
| Имя прилагательное | 9 | Различать имена прилагательные, правильно употреблять в речи формы степеней сравнения. |
| Местоимение | 7 | Просклонять личные местоимения. Различать падежные формы личных местоимений |
| Частицы | 4 | Различать частицы да, дә, та, тә от аффиксов местно-временного падежа –да, -дә, -та, -тә. |
| Послелоги | 3 | Употреблять послелогов с именами существительными и местоимениями в разных падежах. |
| Синтаксис. Предложение | 10 | Определять члены предложения: главные (подлежащее и сказуемое), второстепенные. Находить главные члены предложения. |
| Словосочетание | 6 | Различать предложения, словосочетания, слова, главного и зависимого слова в словосочетании. |
| Развитие речи | 23 | Владеть нормами речевого этикета в общении со сверстниками и взрослыми.<br>Знать: понятия «текст», «абзац», «план текста»; что значит начало и окончание текста, Составлять план к заданным текстам, выделять абзацы, находить связь предложений в тексте, сочинять тексты разных видов по плану. Различать понятия «текст-описание», «текст- повествование». |

## Аңлатмалы язу.

**“Татар теле”  укыту предметы ның эш программасы түбәндәге норматив  документларга нигезләнеп төзелде:**

1. РФ “Мәгариф турында”гы Законы (№273 –ФЗ  29.12.2012 ел);
2. РТ “Мәгариф турында”гы Законы (№68-ЗРТ 22.07. 2013 ел);
3. 06.10.2009 нчы елда РФ Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан расланган “Гомуми башлангыч белем бирү федераль дәүләт  стандартын гамәлгә кертү” турындагы боерыгына (Приказ №373);
4. “Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районы Бишнә төп гомуми белем мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесенең 2023-2024 нче уку елына укыту планы;
5. “Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районы Бишнә төп гомуми белем мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесенең Уставы
6. “Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районы Бишнә төп гомуми белем мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесенең педсовет утырышының 2023 нчы елның 31 августы 1нче № лы боерыгы белән расланган укытучының эш программалары турында нигезләмә;
7 Дәүләт стандартының Федераль компонентына нигезләнгән башлангыч мәктәпләрнең татар теле фәненнән үрнәк программасы.

## Укыту предметының гомуми характеристика

Перспектив башлангыч мәктәпнең 1-4 сыйныфында укучылар аваз белән хәрефне аерырга өйрәнәләр, сүз басымы, исем, сыйфат, фигыль турында башлангыч мәгълүмат алалар. Балалар сөйләм берәмлеге буларак җөмлә турындатөшенчә ала, терминнарны әйтмичә генә , җөмләдәге баш кисәкләрне, өстәмә предметны белдергән сүзләрне һәм ярдәмче сүзләрне табу һәм урынын билгеләү кебек эш төрләренә өйрәнә. Дәресләрдә җөмләләрне төрле тавыш белән әйтү, сүзләрдән җөмләләр, җөмләләрдән кечкенә хикәяләр төзи белү күнекмәләре булдырыла.

Дәресләрдә укучыларның сөйләменә хас булган ялгышлар төзәтелә, аларны булдырмас өчен дәресләрдә балаларга атап чыгарылган газета-журналлардан, китаплардан да файдаланырга мөмкин.

Укытучы балаларның сүзлекчә булдыруларын һәм өйрәнелә торган сүзләрнең махсус дәфтәргә язып баруларын таләп итә.Еш кына шул сүзләр белән сүзтезмә һәм җөмләләр төзетү. Аларны диалог һәм монологлар төзүдә файдалану укучыларның сүз байлыгын арттырачак, бәйләнешле сөйләм үстерүгә ярдәм итәчәк. Әлеге сүзлекне даими рәвештә тикшереп тору укучыларның сүз белән эшли белү дәрәҗәсен өйрәнү өчен дә кирәк булачак.

Сөйләм телен үстерү, сүз байлыгын арттыру төрле язма эшләр үтәгән вакытта да алып барыла. Сүзлек һәм аңлатмалы диктантлар, укытучы биргән җөмләләрне (яки зур булмаган текстны) күчереп язу, матур язу күнегүләрен үтәү кебек эшләр дә андый күнекмәләр булдырырга ярдәм итә. Билгеле, мондый язма эшләр балаларның яшь үзенчәлегенә туры китереп, телне белү дәрәҗәсен истә тотып сайланган текст белән була.

Сөйләм телен үстерү уку дәресләре белән бергә дәвам иттерелә. Татар теле дәресләрендә халык авыз иҗаты үрнәкләреннән табышмаклар, мәкаль-әйтемнәр, санамышлар ятлау, аларны дәфтәргә дөрес һәм матур итеп язып кую дабалаларны татарча аңлаешлы, әдәби нормаларга туры килердәй итеп сөйләргә өйрәтүдә зур әһәмияткә ия булып тора. Укучыларның мәгълүматлылыгын арттыру өчен, дәресләрдә күренекле татар язучыларының әсәрләреннән өзекләр куллану, татар композиторлары, рәссамнары һәм сәнгатьәһелләре турында әңгәмәләр оештыру нәтиҗәле булачак.

**Башлангыч сыйныфта предметны өйрәнүнең максатлары һәм бурычлары.**

Татар теленнән гомуми башлангыч белем бирүнең **максатлары**:

- татар телендә аралашу күнекмәләре булдыру;
- тел чараларын аралашу эчтәлегеннән чыгып сайлый белергә өйрәтү;
- тел белеменең фонетика, лексика, грамматика бүлекләре буенча башлангыч белем бирү, өйрәнелә торган тел берәмлекләрен тикшерә һәм куллана белү

күнекмәләрен булдыру;

- сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләре буенча күнекмәләр формалаштыру;
- укучыларда татар теленә хөрмәт һәм ихтирам тәрбияләү, телнең чисталыгын, дөреслеген саклау. Телне, халыкның рухи мирасын өйрәнүгә кызыксыну уяту.

Тәкъдим ителә торган программада татар теленә өйрәтүнең **бурычлары** түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Укучыларда ана телен өйрәнүгә кызыксыну, омтылыш, эзләнергә теләк уяту, үз милләтеңә, телеңә мәхәббәт тәрбияләү кебек уңай сыйфатлар булдыру.

Балаларга татар теленең төрле бүлекләре буенча белем бирү:

а) фонетика,лексика грамматикага караган башлангыч мәгълүмат бирү;

ә) телебезнең орфоэпиясе, лексикасы, грамматикасы, пунктуациясе буенча күнекмәләр булдыра башлау. Хәрефләрдән иҗекләр һәм сүзләр, сүзләрдән сүзтезмәләр һәм җөмләләр төзергә өйрәтү.

3. Укучыларны дөрес,матур итеп укырга, укыганның эчтәлеген сөйләргә, аерым темалар буенча әңгәмәләр кора белергә, аралашканда тел чараларыннан урынлы файдаланырга өйрәтү.

4. Телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләре булдыру.

5. Укучыларда татар мәдәниятенә караган мәгълүматлылыкны үстерү.

## Уку фәненең уку планында тоткан урыны

Татар теле 3 сыйныфта атнага 4 сәг исәбеннән- 136сәг (34 уку атнасы) укытыла.

**Укытуның планлаштырылган нәтиҗәләре**

**Шәхси нәтиҗәләр:**

-туган ил һәм халкың һәм тарих өчен горурлык хисе кичерү; үзеңнең милли һәм этник яктан  кая керүеңне аңлап, рухи кыйммәтләр булдыру;
-дөньга, аның табигать, халык, мәдәният, дин бергәлегенә карата тулы социаль юнәлештәге караш формалаштыру;
-башкаларның хис-тойгыларын аңлау, борчылу, кайгы-шатлыгын уртаклашу.
-Үз хисләреңне, тойгыларыңны атый һәм аңлата белү;
-Башка кешеләрнең хис-тойгыларын таный белү, башкаларга теләктәшлек күрсәтә белү; ярдәм итә белү;
-Сөйләм матурлыгын күрә, аның белән соклана белү; үзеңнең сөйләмеңне сәнгатьле итәргә тырышу;
-Укырга теләк булу;
-Телне өйрәнүгә теләк булу;
-Әйткән һәм язган сүзләрең өчен җаваплылык хисләре булу;
Бу нәтиҗәләргә ирешүнең ысуллары булып, дәреслектәге текстлар, алар буенча сораулар һәм биремнәр, проблемалы диалоглар тора.
**Метапредмет нәтиҗәләр:**

-укытучы ярдәмендә уку эшчәнлегенең максатын билгеләү һәм формалаштыру;
-иллюстрация белән эш вакытында үзеңнең фикереңне, күзаллавыңны әйтергә өйрәнү;
-укытучы тәкъдим иткән  план буенча эшләргә өйрәнү;
-дәреслек белән эшләү күнекмәләре булдыру;
-шигырьне сәнгатьле уку һәм хикәяне эзлекле  сөйли алуга ирешү;
-үз фикереңне телдән һәм язмача белдерергә өйрәнү;
-уку бурычларын аңлау, аны чишү юлларын эзләү;

-“Татар теле” дәреслеге эчтәлеге буенча материаль һәм информацион мөхиттә эшли алу.
-Мөстәкыйль рәвештә дәреснең темасын һәм максатын билгеләү.
-Эшчәнлек өчен эш урыны әзерләү.
-Эшне планлаштырырга өйрәнү.
-Эшнең дөреслеген тикшерү.
-Эш сыйфатына бәя бирә белү.
-Эш барышында гади генә эш приборлары белән эш итә белү (линейка, бетергеч, карандаш, сүзлек дәфтәре).
-Укытучы белән бергәләп билге кую критерияләрен чыгару.
-Дәреслек белән эш итә белү.
-Текстны (хикәя, шигырь, әкиятне) сәнгатьле итеп уку.
-Текстта очраган таныш сүзләргә таянып, яңа сүзләрнең мәгънәсен төшенү.
-Текстны сәнгатьле итеп укыгач, сорауларга җавап бирү.
-Укытучының авыр булмаган сорауларына җавап бирә, тиешле мәгълүматны дәреслектән таба белү.
-Предметларны чагыштыра, охшаш һәм аермалы якларын билгели белү.
-Укылган яки тыңланган текстның эчтәлеген сөйли белү.
-Төрле сүзлекләрдән куллана белү.
гомуми уку күнекмәләрен һәм үз эшчәнлегеңне оештыра алу сәләтен формалаштыру;
-Дәрестә һәм төрле ситуацияләрдә диалогта катнаша белү.
-Укытучының, классташларының сорауларына җавап бирү.
-Сөйләм этикеты нормаларын үтәү: исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт белдерә белү.
-Башкаларның сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү.
-Парларда эшли белү.

**Предметлы нәтиҗәләр:**

-Телнең милли аңның нигезе булуы турында беренчел белемнәр формалаштыру;

-Татар теленең нормалары турында башлангыч белем күнекмәләре алу;
-Сүзләрне дөрес, аңлап алу;
-Телнең төзелеше, системасы турында белемнәр булдыру, телнең төп бершмлекләрен, аларның билгеләрен, аермалы якларын өйрәнү;
-Телнең төп берәмлекләрен, грамматик категорияләрен танырга һәм анализларга өйрәнү, тел берәмлекләрен дөрес итеп куллана белү.

**Фәнне үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре**

**3 сыйныф укучылары белергә тиеш:**
-сүзнең мәгънәле кисәкләре;
-тамыр һәм кушымча, ясагыч һәм төрләндергеч кушымча;
-сүз төркемнәре: исем, сыйфат, фигыль, кисәкчә, бәйлек;
-җөмләнең баш кисәкләре: ия һәм хәбәр;
-җөмләнең иярчен кисәкләре.
**3 сыйныф укучылары ия булырга тиешле күнекмәләр:**
-үтелгән орфограммалар (калын һәм нечкә сузыклар, яңгырау һәм саңгырау тартыклар, парсыз тартыклар, нечкәлек һәм аеру, калынлык һәм аеру билгеләре, кушма һәм парлы сүзләр, тамырда авазлар чиратлашуы, кисәкчәләр) кергән 55-60 сүзле текстны, җөмлә ахырында тиешле тыныш билгеләрен куеп, диктант итеп язу; текстларны грамоталы һәм каллиграфик дөрес күчереп язу;
-сүзләрне төзелеше ягыннан тикшерү;
-сүз төркемнәрен һәм аларның грамматик билгеләрен тану, аеру ( исемнең санын, килешен, фигыльнең затын, заманын);
-берлек сандагы исемнәрне килеш белән төрләндерү;
-фигыльне заман формаларына куя белү;

-текстта синонимнарны һәм антонимнарны таный, сөйләмдә куллана белү;
-сораулар ярдәмендә җөмләдә сүзләрнең бәйләнешен билгеләү, сүзтезмәләрне аеру, сүзтезмәдәге иярүче һәм ияртүче сүзләрне аеру;
- җөмлә тикшерү;
-җөмләне дөрес интонация белән әйтү;
-бергәләп төзегән план буенча 70-85 сүзле изложение язу;
-текстның темасын һәм төп фикерен билгеләү;
- текстны мәгънәле кисәкләргә бүлү;
-кызыл юлны саклау;
-текстның мәгънәле кисәкләре арасында бәйләнеш булдыру;
-текст кисәкләре,җөмләләр арасында бәйләнеш булдыру;
- темасыннан яки төп фикереннән чыгып, текстка исем кую;
-хикәяләү, тасвирлау һәм фикер йөртү характерындагы текстларны аера белү;
-шәхси тәҗрибәгә, сюжетлы картинага таянып, сочинение язу;
-фикер йөртү характерындагы җавап төзеп әйтү.

**Эш программасының төп эчтәлеге**

**Лексика. Сүз.**

Сүз һәм аның лексик мәгънәсе.Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр, аларның аермасы.Сүзнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре,аларны сөйләмдә куллану. Татар телендә алынма сүзләр.Синонимнар һәм антонимнар, омонимнар: аларны сөйләмдә куллану. Татар теленең сүзлек байлыгы.Татар телендә сүзлекләр: татар теленең аңлатмалы сүзлеге, синонимнар, антонимнар, омонимнар сүзлекләре һәм аларны көндәлек тормышта , уку эшчәнлегендә куллану.

**Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы**

Сүзнең мәгънәле кисәкләрен билгеләү: тамыр һәм кушымча. Сүз ясагыч кушымчалар турында төшенчә. Сүзне төзелеше буенча тикшерү.

Тамырдаш сүзләр турында төшенчә. Аларның синонимнардан һәм омонимнардан аермасы. Тамырдаш сүзләр һәм бер үк сүзнең төрле формалары.

Сүзләрнең дөрес язылышын тикшерү ысуллары: сүзнең формасын үзгәртү, тамырдаш сүзләр сайлау, орфографик сүзлек куллану.

**Морфология**

Сүз төркемнәре турында төшенчә.

**Исем.** Мәгънәсе һәм кулланылышы. Берлек һәм күплек саннары. Күплек сан кушымчаларының дөрес язылышы. Татар телендә килешләр һәм аларның сораулары. Исемнәрнең килеш белән төрләнеше. Исемнәргә морфологик анализ ясау күнегүләре.

**Фигыль.** Фигыльнең мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. Фигыльнең барлык һәм юклык формалары. Фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. Хикәя фигыльнең хәзерге, үткән һәм киләчәк заманнары. -ар, -әр, -ыр, -ер, -р, -ачак, -әчәк, -ячак, -ячәк киләчәк заман хикәя фигыль кушымчаларының дөрес язылышын гамәли үзләштерү.

Фигыльләргә морфологик анализ.

**Сыйфат.** Мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. Сыйфат дәрәҗәләре: гади(төп), чагыштыру, артыклык, кимлек. Чагыштыру дәрәҗәсендәге –рак, -рәк кушымчаларының һәм артыклык дәрәҗәсендәге кисәкчәләрнең дөрес язылышы.

**Алмашлык.** Алмашлык турында гомуми күзаллау.Зат алмашлыклары, мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше.

**Кисәкчә**. *да, дә, та, тә* кисәкчәләрен *–да, -дә, -та, -тә* урын-вакыт килеше кушымчаларыннан аерып таный белү ысуллары. Кисәкчәләрнең дөрес язылышы.

**Бәйлекләр**, аларның сөйләмдәге әһәмияте. Бәйлекләрне исемнәр һәм алмашлыклар белән төрле килешләрдә куллану.

## Синтаксис

**Җөмлә**. Әйтелү максатыннан чыгып, җөмләләрнең төрләре(хикәя, сорау, өндәү(боеру), тойгылы). Җөмлә ахырында тыныш билгеләре: нокта, сорау һәм өндәү билгеләре. Хикәя, сорау, өндәү(боеру), тойгылы җөмләләрнең интонацион үзенчәлекләре(гамәли үзләштерү).

Баш һәм иярчен кисәкләр турында төшенчә. Ия һәм хәбәр. Җөмләдә сүзләр бәйләнешен билгеләү.

Җөмләдә сүз тәртибе. Җыйнак һәм җәенке җөмләләр турында төшенчә.

**Сүзтезмә**. Сүз, сүзтезмә, җөмләнең охшаш һәм аермалы яклары. Сүзтезмәдәге ияртүче һәм ияртүче сүзләрне таный белү.

## Бәйләнешле сөйләм

Текст. Текстның темасын, төп фикерен билгеләү, абзацларга бүлү. Тасвирлаучы һәм хикәяләүче текстларның төп үзенчәлекләре.

Сөйләм этикасы белән таныштыру.

## Тематик планлаштыру

| | | |
|---|---|---|
| **1-2 сыйныфларда өйрәнгәннәрне кабатлау** | **16** | Яңгырау, саңгырау тартыкларны һәм сузык авазларны танып белү; өйрәнгән орфограммаларны табу һәм сүзнең дөрес язылышын аңлату, орфографик сүзлекләр куллану.<br><br>Сүзләрне иҗекләргә бүлү һәм аларның санын билгеләү. Иҗекләргә бүлеп, сүзләрне юлдан-юлга күчерү. Сүзләрне юлдан-юлга күчергәндә ясалган хаталарны төзәтә белү.<br><br>Орфографик һәм орфоэпик сүзлекләр белән эшләгәндә, алфавиттан файдалану. |
| **Лексика. Сүз** | **10** | Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләрне, сүзнең туры һәм күчерелмә мәгънәләрен танып белү; текстларда, үз сөйләмендә күчерелмә мәгънәле сүзләрне куллана белү.<br><br>Тамырдаш сүзләрне синонимнардан һәм омонимнардан аера белү. Тексттан синоним һәм антонимнарны билгеләү. |
| **Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы** | **9** | Сүзләрне тамыр һәм кушымчаларга аеру.<br><br>Тамырдаш сүзләрнебилгели алу. Сүз ясалыш ысулларын танып белү. |
| **Морфология**<br><br>**Исем** | **16** | Исем, сыйфат, алмашлык, фигыль сүз төркемнәрен танып белү.<br><br>Җанлы һәм җансыз, ялгызлык һәм уртаклык исемнәрне тану; исемнәрне килеш, сан белән төрләндерү, килешләрнең исемнәрен дөрес әйтү. |
| **Фигыль** | **27** | Фигыльләрне заман, зат-сан белән төрләндерү. Хәзерге, үткән, киләчәк заман хикәя |

| | | |
|---|---|---|
| | | фигыльләрне зат-сан белән төрләндерү. |
| **Сыйфат** | **9** | Сыйфатларны таный алу, сыйфат дәрәҗәләрен сөйләмдә дөрес куллану. |
| **Алмашлык** | **7** | Зат алмашлыкларын килеш белән төрләндерү. Кушымчаларына карап, зат алмашлыкларының кайсы килешкә каравын билгеләү. |
| **Кисәкчә** | **4** | да, дә, та, тә кисәкчәләрен –да, -дә, -та, -тә урын-вакыт килеше кушымчаларыннан аера белү. |
| **Бәйлекләр** | **3** | Бәйлекләрне исемнәр, алмашлыклар белән төрле килешләрдә куллану. |
| **Синтаксис.**<br>**Җөмлә** | **10** | Җөмләнең баш(ия, хәбәр), иярчен кисәкләрен билгеләү. Җөмләнең баш кисәкләрен табу. |
| **Сүзтезмә** | **6** | Җөмлә, сүзтезмә, сүзне, сүзтезмәдәге ияртүче, иярүче сүзләрне аера белү. |
| **Сөйләм үстерү** | **23** | Яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән аралашканда сөйләм этикеты нормаларына ия булу. “Текст”, “абзац”,“текст планы”; текстның башы һәм ахыры төшенчәләрен белү. Бирелгән текстларга план төзү, абзацларны билгеләү, тексттагы җөмләләрнең бәйләнешен билгеләү. |

## Норма оценивания\ Бәяләү критерияләре

**Контроль күчереп язуны бәяләү**

Пөхтә, төгәл һәм орфографик хатасыз язылган эшкә “5”ле куела.

Пөхтә, төгәл язылган, әмма 1 – 3 төзәтү яки 1 – 2 орфографик хатасы булган эшкә “4”ле куела.

Пөхтә һәм төгәл язылмаган, 4 – 5 төзәтү яки 3 – 5 орфографик хатасы булган эшкә “3”ле куела.

Пөхтә һәм төгәл язылмаган, 6 яки артыграк орфографик хатасы булган эшкә “2”ле куела.

**Диктантны бәяләү**

Пөхтә һәм төгәл язылган, 1 орфографик хатасы булган диктантка “5”ле куела.

Пөхтә һәм төгәл язылган, 2 – 3 орфографик хатасы булган диктантка “4”ле куела.

Пөхтә һәм төгәл язылмаган, 4 – 6 орфографик хатасы булган диктантка “3”ле куела.Пөхтә һәм төгәл язылмаган, 7 яки артыграк орфографик хатасы булган диктантка “2” куела.

**Язма сөйләмне бәяләү**

2 – 4 нче сыйныфларда укучыларның язма сөйләм күнекмәләрен үстерү өчен, өйрәтү характерындагы изложениеләр һәм сочинениеләр яздырыла. Аларны бәяләгәндә, түбәндәгеләрне исәпкә алу сорала: эшнең эчтәлеге ягыннан тулы һәм эзлекле язылуы, грамоталы булуы. Башлангыч сыйныфларда изложение һәм сочинениеләр өчен бер билге куела.

Тәкъдим ителгән эзлекле язылган, 1 орфографик һәм 1 пунктуацион яки 1 грамматик хатасы булган эшкә “5”ле куела.

Тәкъдим ителгән темага эзлекле язылган, ләкин эчтәлектә ялгыш җибәрелгән, 2 -3  орфографик һәм пунктуацион яки 2 – 3 грамматик хатасы булган эшкә “4”ле куела.

Тәкъдим ителгән темага эзлекле язылмаган, 4 – 6 орфографик һәм пунктуацион яки 4 – 6 грамматик хаталы эшкә “3”ле куела.

Тәкъдим ителгән темага эзлекле язылмаган һәм эчтәлеге ачылмаган, 7 дән артык орфографик һәм пунктуацион яки 7 дән артык тупас грамматик хатасы булган эшкә “2”ле куела.
**Тест** биремнәре түбәндәгечә бәяләнә:
“2”ле – 5 тән кимрәк дөрес җавап.
“3”ле – 5 дөрес җавап.
“4”ле – 7 дөрес җавап.
“5”ле – 10 дөрес җавап.

## Методическое обеспечение\Методик кулланма

1.Татар теле, /Казан, “Мәгариф – Вакыт” нәшрияты, 2012/,И.Х.Мияссарова, К.Ф.Фәйзрахманова/. 2 кисәктә.

2. Татар теле дәреслекләренә мультимедиа кушымта . “Татар теле”, 3 класс, Мияссарова И.Х., К.Ф.Фәйзрахманова

3. И.Х.Мияссарова, К.Ф.Фәйзрахманова “Татар телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 3 нче сыйныфында эшләүче укытучылар өчен методик кулланма”, К.-“Мәгариф-Вакыт”, 2012

**Өстәмә ресурслар:**

Ахиярова М.Җ. “Татар теленнән иҗади сочинениеләр һәм изложениеләр язарга өйрәтү” 1 – 4. /Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2009/

Абдрәхимова Я.Х. Татар теленнән диктантлар. 1 – 4. /Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2009/

**Интернет –ресурслар:**

Татар телендә белем һәм мәгълүмат бирүче http://tatarschool.ru/, belem.ru, tazbash.narod.ru/ сайтлары

**Укытуның техник чаралары**
1. Укытучы ноутбугы.
2. Мультимедиа проекторы.

3. Доккамера.

**Лист корректировки\Төзәтмәләр кертү бите.**

| Название раздела, темы\Бүлек, теманың исем | Причина корректировки/ Төзәтмәләр кертү сәбәбе | Корректирующие мероприятия\Төзәтмә кертү чаралары | Дата проведения \ Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|
| | | | План | Факт |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |